**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 11 декабре № 2173

Кама Тамагы районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы, махсус хәрби операциядә катнашучы граждannар гаиләләреннән булган балаларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү турында» 2022 елның 9 декабрендәге 1339 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән булган балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү турында» Кама Тамагы районы Башкарма комитетының 2022 елның 9 декабрендәге1339 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән бҗулган балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү турында» 2022 елның 09

декабрендәге 1339 номерлы карарының 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрбиләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категория гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән булган ,Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә башлангыч, төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы балаларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итәргә:

- көненә 28,8 сум - ата-ана түләве;
- 18,00 сум - озынайтылган көн төркеменең ата-аналар түләве;
- 9,20 сум - республика субсидиясе».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Х. Хәбибулловага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Баржанов